Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ

12+

№2 (132)

26 февраль 2015 ел




КФУ студенты Туран Гатауллин. Влад Михневский фотосы.

# Сәламәт тәндә – сәламәт акыл

1 НЧЕ МАРТТАН ЯЗ БАШЛАНА! КӨННӘРЕГЕЗ ЯКТЫРАК, ҖЫЛЫРАК, НУРЛЫРАК БУЛУЫН ТЕЛӘП КАЛАБЫЗ. Ә ШУЛАЙ ДА БЕРЕНЧЕ КОЯШЛЫ КӨННӘРГӘ ЫШАНЫП БЕТӘРГӘ ЯРАМЫЙ. БЕЛГЕЧЛӘР ИГЪТИБАРЛЫРАК БУЛЫРГА ЧАКЫРА. САУЛЫКНЫ САКЛАП КАЛУ СЕРЛӘРЕН 3 БИТТӘ, РАУШАНИЯ ГАЙФУЛЛИНА КИҢӘШЛӘРЕНДӘ ТАБА АЛАСЫЗ.

• Белми калма!




## «Пи» туган көненә чакыра

2015нче елның 26нчы мартында Санкт-Петербург дәүләт университетының Халыкара мөнәсәбәтләр факультеты «Дөнья күләмендә Россия: яңа тәкъдимнәр һәм мөмкинлекләр» – студентларның өченче Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясен уздыра.

Оештыручылар халыкара мөнәсәбәтләр, халыкара хокук, дөнья икономикасы белгечлеге буенча белем алучы магистратура, бакалавриатура студентларын конференциядә катнашырга чакыра. Гариза һәм тезисларыгызны 16 нчы мартка кадәр ***sirconf@yandex.ru*** адресы буенча җибәрә аласыз.

• • • •

2015 нче елда КФУның Алман телендә белем бирү, фән һәм мәдәният үзәге 10 еллык юбилеен билгеләп үтәчәк. Шул хөрмәттән ДААД, КФУның Туктаусыз белем бирү институты, ТР Алман йорты, КФУның Тел институты, Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе, «Казанский университет» газетасы һәм КФУның студентлар телевидениясе «Алман теле белән яңа мөмкинлекләр» олимпиадасын уздыра. Җиңүчегә төп бүләк – ДААД стипендиясе.

Олимпиада ике номинациядә уза. Беренче номинациядә A2/B1, икенчесендә B1/B2 дәрәҗәсендә тел белүчеләр катнаша алачак.

Ярыш өч баскычтан тора: 1нче баскыч – өй эше – «Warum ich Deutsch lerne» соравына җавап рәвешендә төшерелгән видеоролик һәм «Ich und Deutschland» темасына эссе. 2 нче баскыч тесттан гыйбарәт. 3 нче турда билгеләнгән темага дебат уздырылачак.

Нәтиҗәләр һәм җиңүчеләрне бүләкләү 17 нче апрель көненә билгеләнгән.

• • • •

Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтында 2015 нче елның 16 нчы апрелендә студентларның Республикакүләм конференциясе – «Бөек Ватан сугышы: нәтиҗәләр һәм сабаклар» узачак. Әлеге чара җиңүнең 70 еллык юбилеен багышлана һәм студентларны Бөек Ватан сугышы тарихының актуаль мәсьәләләре турында фикер алышуга чакыра.

Тулырак мәгълүматны университетыбыз сайтыннан ала аласыз.

Конференциядә катнашу өчен гаризаларны 13 нче апрельгә кадәр ***kpfu–pobeda70-2015@yandex.ru*** адресы буенча кабул итела.

• • • •

Яндекс, КФУ белән берлектә, математикадан Россиякүләм контроль эш уздырачак. «Что и требаволось доказать» дип исемләнгән әлеге бәйгедә барлык теләүчеләр катнаша ала. Чара математиканың көндәлек тормышта кирәк булуын дәлилләүне максат итеп куя. Контроль эш «Пи» саны көнендә, ягъни 14 нче мартта сәгать көндезге 12 дә узачак. Казанлылар биремнәрне интернет челтәрендә онлайн, яки Казан федераль университеты мөгаллимнәре карамагында, аудиторияләрдә эшли ала.

Казан федераль университеты профессоры Мөкатдәс Миссаров әйтүенчә, Җиһан математика кануннарына нигезләнә, шуңа күрә әлеге фәнне туган тел белән бертигез дәрәҗәдә белергә кирәк!

• Ректорат

# Университет позицияләрен ныгыта

**Илмир ВӘЛИЕВ,** Математика һәм механика институты


Инна Басыйрова фотосы

24нче февраль көнне ректор Илшат Гафуров җитәкчелегендә ректоратның чираттагы утырышы булды.

Җыелыш тантаналы башланды: КФУның Фундаменталь медицина һәм биология Институты директоры, профессор А.Киясовны туган көне белән тәбрикләделәр. Соңрак сүз университетның бөтендөнья рейтингларында тоткан урыны һәм Томск шәһәрендәге «5:100» офис проектының нәтиҗәләре турында алып барылды. Бу хакта тулырак институт-филиаллар һәм факультетларның конкурентлылыгын арттыру буенча юл карталары һәм КФУ идарәсе органнарындагы үзгәрешләр белән Икътисад һәм стратегик үсеш мәсьәләре буенча проректор **М.Сафиуллин** таныштырды. «Томскида әйтелгән кисәтүләр тулысынча бөтен программага да кагыла. Программада катнашучыларның бөтенесен дә бертигез бәяләргә ярамый. Һәркем үз эше өчен җаваплы. Бездән шулай ук яңа проектлар эшләп җибәрү таләп ителә...», – диде проректор.

Проект кысаларында, Томск шәһәренә эш сәфәре нәтиҗәләре буенча, университетыбыз көчле адымнар белән алдынгылар сафына омтыла. Узган елны 15 катнашучы арасыннан 11нче урында булсак, хәзер исә – алтынчы баскычта!

Уку йортыбыз дөньякүләм әйдәп бара торган вузлар күрсәткечләренә якынаюга юнәлтелгән үсеш программаларында бик актив катнаша. Шуларның берсе – «юл карталары». Киңәшмәдә әлеге программага аеруча зур игътибар бирелде. 15нче мартка кадәр университетның 2015-2016 еллар исәбенә төзелгән «юл карталары»на үзгәртүләр кертү мөмкинлеге бар. Утырыш барышында ук институт директорлары белән «юл карталары»ның үтәлеше турындагы килешү кабул ителде. Әлеге килешү җаваплылыкны концентрацияләүгә юнәлтеләчәк.

Чит ил студентларына уку өчен түләү мәсьәләсе дә кузгатылды. Сумга карата доллар курсының үзгәрүе белән, алга киткән Россия университетларының конкурентлык сәләте дә күпкә көчәйде. Бу хакта ректор И.Гафуров КФУда Европа илләренә хас булган затлылык һәм эш барышында нәкъ менә студентларга ориентлашу булырга тиешлеген ассызыклады.


Алга таба КФУның Интернет челтәрендә алга китеше һәм Вэбометрикс сайтларының рейтинглары турында сүз алыштылар. Бу юнәлештәге позицияләрне яхшырту максатыннан, җитәкчеләр тарафыннан унга якын тәкъдим әйтелде. Шулар арасында хезмәткәрләрнең шәхси сәхифәләрен тиешле дәрәҗәдә тутыру, студентларның курс, чыгарылыш, диссертация эшләрен университет сайтына урнаштыру, институтларда булачак мөһим чаралар турында мәгълүмат бирүче атналык дайджестлар булдыру һ.б.

Беренче кварталда әлеге эшчәнлек нәтиҗәсе KPFU.RU сайтының, хезмәткәрләрнең шәхси сәхифәләре тутырылуы нәтиҗәләре нигезендә бәяләнәчәк.

• Чара

# Япония татарча өйрәнә!

**Айгөл АБДРАХМАНОВА**



Университетыбыз тормышы бер генә мизгелгә дә туктап тормый. Беләсегез килсә, һәр ел биредә дистәләрчә фәнни-гамәли конференция һәм укулар үткәрелә. Һәр сәгать, һәр минут студентлар тормышын уңай якка бора, тормышка булган мөнәсәбәтен үзгәртә, истәлекле датаны хәтергә сеңдереп калдырырга тырыша. 21 февраль дә шундыйлардан иде.

Студентларның һәм мөгаллимнәрнең көне «Татар лингвокультурологиясе: проблемалар һәм перспективалар» дип исемләнгән гомуми урта, махсус урта һәм югары белем бирү йортларында укучыларның VI Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе белән башланып китте. Әлеге чарада бөтен Рәсәйдән җыелган 101 мәктәп укучысы һәм 125 студент көч сынашты. Катнашучыларның гаять катлаулы һәм мөһим мәсьәләргә туктапулары, билгеле бер проблемадан чыгу юлларын эзләүләре жюри әгъзаларын, укытучыларны куандырды. Секция утырышында, Япониядән килеп, Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара бәйләнешләр бүлеге магистратурасында белем алучы Хисиямо Ютоның булуы катнашучыларны тагын да дәртләндерде. Сүз уңаеннан, чит илдән Казанга килеп, татар теле өйрәнүчеләр аз түгел. Алар, белем алудан тыш, мәктәпләргә очрашуларга, ТВ-тапшыруларга, төрле мәдәни чараларга да еш йөри. Ә киләсе санда татарча гына сөйләшә торган япон егете белән фин егетенең Казан мәктәпләрендәге маҗаралары турында да укый аласыз... Алар кем, каян һәм ничек Казанга килеп эләккән, аларның татар кызлары турындагы фикерләре, беренче сессиядән соңгы хискичерешләре – барысы да киләсе санда!



Фән өлкәсендә эзләнүләре, тирән белемнәре белән аерылып торган укучылар һәм студентлар конференция азагында дипломнар белән бүләкләнде. Соңгы вакытта мөгаллимнәр арасында төшенкелеккә бирелүчеләр, җәмәгатьчелек арасында телне саклап кала алмаячагыбыз хакында сөйләүчеләр, бүгенге татар яшьләрен тәнкыйть итүчеләр шактый. Ә без менә шушы залда җыелучыларга күз төшерик: я, гыйлемгә тартылган, гыйлемне үстергән яшьләр өметсез була аламы?!

Җитди нотада башланып киткән көнгә күтәренке кәеф, иҗадилык өстәү мәслихәт. Шуны истә тотып, Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара бәйләнешләр институты студентлары Туган тел көне һәм Каюм Насыйриның тууына 190 ел тулу уңаеннан тантаналы концерт әзерләгәннәр иде. Конференциядә катнашучыларны һәм килгән кунакларны сәламләү сүзе белән ФМБИның фәнни эшләр буенча директор урынбасары Искәндәр Ярмәкаев чыгыш ясады. Ул Каюм Насыйрины Лобачевский белән тиңләде. Аның татар милләте үсеше өчен башкарган эшенең ни дәрәҗәдә мөһим булуын кат-кат ассызыклады. И.Э.Ярмәкаев чыгышын тамашачыларга изге теләкләр белән тәмамлады: «Һәрбарчагызга, аз булса да, К.Насыйрига охшарга, ул калдырган байлыкны югалтмыйча, үстерергә язсын!» – диде.

К.Насыйри исемендәге Институт директоры Рәсим Хөснетдинов та, К.Насыйри музее директоры Раушания Шәфигуллина да бөек галимнең эшчәнлеге, аның безгә калдырган мирасы, рухи байлыгы турында сөйләп узды. Татар халкын алга җибәрү, Аурупа мәдәнияте белән таныштыруны дәвам итәргә кирәклеге билгеләнде.

Бәйрәмне алып баручылар ТРның Каюм Насыйри исемендәге премия лауреатларына да сүз бирми булдыра алмадылар. Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова, К.С.Фәтхуллова, Л.М.Минһаҗевалар барлык тамашачыларга бөек шәхесләребез тәҗрибәсен тормыш кредосы итүләрен теләделәр.

Кичә азагында студентлар арасында уздырылган «Туган тел тылсымы» эсселар бәйгесенә нәтиҗәләр ясалды. Призлы урыннарга ия булучыларга диплом һәм истәлекле бүләкләр бирелде.

Кыскасы, Япониядә дә татар телен яратып өйрәнүчеләр булганда, без – татарның газиз балалары, К.Насыйри оныклары – Ана телен онытып, чит телләрдә аралаша алмыйбыз. Телсез милләт – канатсыз милләт, ә безнең әле очасылар бар!

**А.Адутова фотолары**

• Юбилей

# Улымны таныганнар кулларымны үбә

Айгөл АБДРАХМАНОВА, Руфинә ГАБДРАХМАНОВА

Университетыбызның бүгенгесенә өлге булырдай 210 еллык тарихын тергезгән КФУ музее директоры Стелла Владимировна Писарева 28 нче февральдә 90 нчы язын каршылый. Аны күрүгә, 90 яшь тула, дип әйтеп тә булмый. Һәрвакыт шаян, җор телле, күзләрендә дәрт–дәрман ялкыны йөртүче бу ханымның тормыш юлы да хикмәтле, гыйбрәтле.



С.В.Писарева Г.С.Әпсәләмов белән

**– Стелла Владимировна, Сез тумышыгыз белән Украинадан. Тормыш юлларыгыз Казанга ничек китерде?**

– Сугыш, эвакуация. Сугыш башланганда, мин әни белән Харьков шәһәрендә яши идем. Шәһәр бомбага тотылган вакытта, безне тылга алып киттеләр, Казанга эләктек. Гадәттә, университетта эшләгән кешеләр «Бу – минем икенче йортым» дияргә ярата. Мин бер дә шикләнмичә әйтә алам: университет, чыннан да, минем өчен туган йортыма әверелде. Хәзерге музей залы эвакуация вакытында тулай торак итеп җиһазландырылган иде, миңа һәм әнигә янәшә ике карават бирделәр, университетта укыдым да, яшәдем дә.

10 нчы сыйныфка күчкән генә вакытым. В.И. Ленин исемендәге 4 нче урта мәктәпне тәмамлагач, 1942 нче елда Казан университетының тарих һәм филология факультетына укырга керү бәхетенә ирештем. Алга таба аспирантурада уку мөмкинлеге дә бар иде, шулай да минем 1 ел тирәсе кайда булса да эшләп карыйсым килде.

**– Эшкә кердегезме?**

– Әйе, фәнни җитәкчем тәкъдиме белән А.М. Горький исемендәге музейга эшкә чакырдылар. Анда бары 1 генә ел эшләп, университетка кайтырга тиеш идем. Ләкин музей эше миңа шулкадәр ошады ки, гомеремнең 18 елын шуңа багышладым. Башта – өлкән фәнни хезмәткәр, аннары – фәнни эшчәнлек буенча директор урынбасары вазыйфаларын башкардым.

Казанда телевидениенең оешып кына килгән вакыты. Сценарийлар язарга, чыгышлар ясарга еш туры килде. Аннары бер әдәби тапшыруның редакциясенә эшкә чакырдылар. Уйландым да, музей өлкәсен калдырып, Казан телевидениесендә үземне сыныйсым килде. ТАССРның Дәүләт музее (хәзерге Милли музей) җитәкчесе Владимир Дьяконов, моны белеп алу белән, үзенә чакырып, бу адымнан туктатты. Владимир Михайлович музейда ачылачак Татарстан әдәбияты бүлегенә җитәкче итеп мине куярга тели икән. Тәкъдимен кире кага алмадым. Бу сөйләшү 1964 нче елның август аенда булса, октябрьдә яңа эшкә керешкән идем инде.

**– Ә университет музее?**

– Күп тә үтмәде, университеттан кешеләр килеп, мине башка эшкә чакыра башладылар. Гади генә эш түгел әле ул: университетның 175 еллык юбилеена тарих музее булдырырга телиләр икән. Озак кына бу тәкъдимнән баш тартып йөрдем, чөнки вакыт аз калып килә, ә тарихны өйрәнү, экспонатларны юллау җиңел эш түгел. Тора–бара күндем.



С.В.Писарева Е.А. Евтушенко белән

1978 нче елда музейны оештыру эшенә керештем. Партком бүлмәсенә өстәл, урындык куйдылар да: «Бер елдан музей ачылырга тиеш!» – диделәр. Ә эш җиңел түгел иде, шулкадәр көч сарыф итәргә туры килде, хәтта гаиләм дә арткы планда калды. Бер ел да ике айдан Казан университетында тарих музее ачылды. Университет җитәкчелеге дә, барлык профессорлар да ярдәм итәргә ашкындылар. Төрле елларда университетыбызда эшләгән галимнәрнең туганнары экспонатлар җыюга үз өлешләрен кертteләр. Кафедра, китапханә, архивларда «яшәргә» туры килде. Тарихи материалларны Казаннан гына эзләмәдем: Мәскәү, Санкт–Петербургка еш йөрдем. Шулай итеп, музей үсә бирде. Казанга килгән һәр кунак университет музеен күрергә тели.

**– Нигә тарих һәм филология факультетын сайладыгыз?**

– Мәктәптә укыганда, иң яраткан фәнем әдәбият булды. Тел белеме белән кызыксынмадым мин. Университетта уку дәверендә дә әдәбият, аның үсеше мәсьәләләре миңа күпкә кызыклы тоелды.

Әдәби иҗатка килгәндә, нишләптер, шигъри әсәрләр дә, проза да язып караганым булмады. Фәнни мәкаләләр язам, күбрәк университет, аның тарихы турында.

**– Стелла Владимировна, сугыш вакытындагы Казан хәтерегездә ничек калды?**

– Шәһәрне күрү белән, аның пычрак һәм суык булуына гаҗәпләндем. Харьковта җылырак климат бит, мондый кышкы суыкларга мин күнекмәгән. Ләкин миңа һәрвакыт уңыш елмаеп торды. Безне башта Раифа урман хуҗалыгына урнаштырдылар. Анда минем киләчәгемә, университетта югары белем алуыма сәбәпче шәхес – баш урманчы Мифтахетдинова Хәнифә Александровна белән таныштым. Ул әни белән дуслашты, бервакыт килде дә миңа: «Болай торып булмый, сиңа укырга кирәк. Җыен, Казанга барабыз. Әнием йортында торырсың, сеңлем Фатыйма белән бергә укырсыз», – диде. Фатыйма (мин аны Фата дип атыйм) – минем тормышымдагы иң якын, мөһим кешеләрнең берсе. 1941 нче елдан бирле дус без.

**– Бәхетле кеше сез.**

– Бәхетем бар, әйе! Гомерем буе бары яхшы кешеләр генә очрады миңа. Балачагым, әти–әниемнән башлап, гел изге күңелле кешеләргә туры килдем. Ләкин авыр чаклар да булмады түгел, булды. 1938 нче елда, мин 13 яшьтә чакта, әтине кулга алдылар, күп тә үтмәде, ул үлем җәзасына тартылды. Шул рәвешле мин әни белән генә калдым.

**– Сугыштан соң туган якларыгызга кайту теләге булгандыр...**

– Юк, ничектер, аның турында уйламадым да. Монда мин кияүгә чыккан идем инде. Ирем Юрий Муравьев бик яхшы кеше иде, Бөек Ватан сугышы ветераны. 1946 нчы елда ул сугыштан кайтты, 1947 нче ел башында без инде өйләнештек. Шулкадәр тугры, ихлас, гадел кеше иде ул, 45 ел буе безне җил–яңгырдан саклап яшәде. Инде 20 елдан артык ялгыз яшим, ләкин янымда куанычым – улым Владимир Муравьев бар. Аны бөтен Казан белә: ул – диагностик, онколог. Аның минем улым икәнне белгәч, кулларымнан үбүчеләр дә булды.

**– Студентларга нәрсә теләр идегез, Стелла Владимировна?**

– Еш кына үз тормышыма, язмышыма гаҗәпләнеп карыйм да серен ачыкларга тырышам. Сере гади икән: үз эшеңне яратып эшләгәндә генә, җан тынычлыгы табып була. Акча эшләү төп максат була алмый. Кайда гына хезмәт куйсаң да, ул авырсынып башкарылырга тиеш түгел, шуңа күрә һәр студент үз урынын тапсын иде.

• Адымнар

# Без армиядә «хитрый» идек...

Азат ЮСУПОВ, КФУ аспиранты

Календарьга карап, никтер туктап калдым: 23нче февраль 2015... Тормыш ыгы-зыгысы белән кайнап, Ватанны саклаучылар көнен онытып җибәрә язганмын.

Кайчандыр армиядән кайткан абыйларга сокланып йөри идек, ә хәзер менә үзем алар сафында. Мин армиядә 2012-2013 нче елларда хезмәт иттем. Аспирантураның беренче елыннан соң, эшем бетә торсын дип, үз теләгем белән киттем һәм вакытында исән-сау әйләнеп тә кайттым. Хезмәт иткәнемә бер тамчы да үкенмим, саусәламәт булган һәр ир-ат армиядә булып кайтырга тиеш дип саныйм. Аллаһ боерса, киләчәктә үземнең балаларым да, һичшиксез, армиядә хезмәт итәчәкләр! Анда үткән елымны бушка узган вакыт дип исәпләмим, фотографияләрне карап утырырга күңелле, үзенә күрә бер горурлык хисләре дә уята.

Бүгенге көндә армиядә «дедовщина» хөкем сөрә, солдатларны кыйныйлар, мыскыл итәләр, мөмкинлегең булса бармый калуың хәерлерәк дигән сүзләрне дә еш ишетергә туры килә. Мин моның белән килешеп бетмим. Дөрес, бардыр андый җирләре дә.

Хезмәт иткән чакта офицер, прапорщиклар: «Армия ике ел булганда солдатларны нәрсәгә дә булса өйрәтеп була, профессия алып кайтып китәләр иде, ә хәзер хәрби эшкә өйрәтү устав ятлаудан, ак яка тегәргә өйрәнүдән, кыш көне кар көрәүдән ерак китә алмый», – дип уфтаналар.

Армиядән кайткач, күпләр анда булган кызык хәлләрне сораштырырга ярата. Шулчак беренче көннәр искә төшә... Бөтен солдатларның башыннан үткән әйбер – беренче тапкыр идән юуу. Юасы килми, әмма, нарядта булгач, юарга тиешсең. Чиләк, су, швабра бирделәр, ә чүпрәк юк, үзеңә табарга кирәк. Ротаның старшинасы да, карт солдатлар да теләсәң кайдан тап диделәр, әмма идән юылган булырга тиеш. Дежур сержант аяк киемнәрен, портянкаларын сушилкага элеп куйды да караватка менеп ятты, ә син теләсәң нишлә. Мин исә, казармада идән юарга яраклы бернинди чүпрәк тә таба алмагач, бернишләр хәл юк, кеше күрмәгәндә, сушилкага кердем дә, тегенең портянкаларын алып, казарма идәнен ялт иттереп юып куйдым. Ахырдан чүпрәкләрне чүпкә ташладым. Сержант портянкасын бер атна эзләде, кемнәрдән генә сорап карамады, әмма таба алмады. Сквозняк, җил белән очып чыгып, туган якларыңа синсез кайтып киткәндер, диеп көлештеләр. Дәшмәдем. Миңа да сүз әйткән кеше булмады. Ярты еллап хезмәт иткәч, әлеге сержантның кайтыр вакыты җитте. Ул кайтып китәсе көнне, мин аңа бу хакта сөйләдем, ачуы килсә дә, «ну, хитрый татарин» диюдән башка берни эшли алмады. Ул китеп, ай ярым узгач, минем портянкалар югалды. Үз-үземә көлдем, минекеләр дә мине ташлап «кайтып киткән», ахрысы.



• Сәламәтлек

Кыш инде ахырына якынлаша, урамда яз исе килә. Шуның белән бергә, табигать кенә түгел, төрле авыру-чирләр дә үзләрен сиздерә башлыйлар. Мәсәлән, авитаминоз һәм гиповитаминоз.

# Сәламәт тәндә – сәламәт акыл

Раушания ГАЙФУЛЛИНА, клиник медицинаның фундаменталь нигезләре кафедрасы доценты



Әлеге авыруларны бутарга һич ярамый. Авитаминоз ул – организмга берничә төрле витаминның җитеп бетмәве булса, гиповитаминоз – конкрет бер витаминның җитмәве. Бу авыру каян барлыкка килә соң диясездер? Сәбәбе төрле булырга мөмкин. Вакытында ашамау, дөрес тукланмау, фаст-фуд белән мавыгу. Көзен җыелган файдалы матдәләр көннән-көн кими. Шуңа да, яз якынлаша барган саен, кеше үзен хәлсезрәк хис итә башлый. Бүген, Интернет челтәренә кереп китеп, үзлегеннән дәваланучылар саны арта бара. Ләкин мавыгып китмәгез. Иң яхшысы, белгечләр белән киңәшеп, тиешле витаминнар алу, дөрес туклану, вакытында ятып йоклау һәм ешрак саф һавада булу.

● Безгә язалар



# «Әкият»тә кунакта!

Раилә ӘХМӘДИЕВА, Иҗтимагый – фәлсәфи фәннәр һәм массакүләм коммуникацияләр институты

Ә СЕЗ МАЙ ЧАБУНЫҢ КАЙЧАН УТКӘРЕЛҮЕН БЕЛӘСЕЗМЕ? ШАККАТМАГЫЗ, ҮЗЕМ ДӘ ӘЛЕГЕ ТЕРМИН БЕЛӘН КҮПТӘН ТҮГЕЛ ГЕНӘ ТАНЫШТЫМ. БАКСАН, БЕЗ БЕЛГӘН МАСЛЕНИЦА БӘЙРӘМЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ МАЙ ЧАБУ ДИП ЙӨРТЕЛӘ ИКӘН!

Май чабу – славян халкына хас булган иң матур һәм иң якты бәйрәмнәрнең берсе. 21 нче февраль көнне студентлар да, дәррәү килеп, әлеге күңелле чарага юл тотты.

Чараның тантаналы ачылышы көндезге 12дә «Әкият» курчак театры каршындагы боз шәһәрчегендә башланып китте. Ял көне булгангамы, мәйданда алма төшәрлек тә урын юк иде. Бәйрәмгә славяннар гына түгел, ә төрле милләт һәм дин вәкилләре дә килгән. Руслар белән беррәттән, татар, әрмән, мари, казах, хәтта африкалылар да әйлән-бәйлән уйнадылар. Менә сиңа интернационал!

Бәйрәмгә чорлар аша килгән кунаклар да бар иде. А.С. Пушкинның үзе белән танышып кайттык! Сәхнә түренә Черномор, Шамахан патшабикәсе, Руслан һәм Людмила да чыкты.

Теләүчеләр боз шәһәрчегенә сәяхәт кыла алдылар. Монда рус курчаклары, агач һәм корычтан ясалган көрәш кирәк-яраклары, бизәнгечләр сатып алырга мөмкин иде. Атлар, дөяләр сабыйларның күңеленә хуш килде. Шамакайлар, бүре, куян, төлке дисеңме – кунакларның күңелен күтәрер өчен бер төркем әкияти зат алан буйлап чабып йөрде. Юни да бар иде араларында.

Май чабу коймаксыз буламыни, диярсез сез. Әлбәттә, юк. Һәркем яңа гына табадан төшкән коймак һәм хуш исле чәй белән сыйлана алды. Саф һавада күңел ачып, туйганчы ял итеп кайттык.

Менә шулай якты йөз белән кышны озаттык. Хәзер исә «Төкле аягың белән, яз!» – диясе генә кала.

Матур Бәлеш

# Золушка, Пигмалион… Юк, Айсылу

Энҗе ИБРАҺИМ, Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты студенты

ЗОЛУШКА, ПИГМАЛИОН… АЙСЫЛУ. БУ ГРАДАЦИЯ ТҮГЕЛ. КҮПЛӘР КЕБЕК, НИЧЕК КЕНӘ АКЫЛ САТАРГА ТЫРЫШЫП, ЯҢА ЧЫККАН «АЙСЫЛУ» ФИЛЬМЫН БАШКА БЕР ӘСӘР БЕЛӘН ЧАГЫШТЫРЫРГА ТЫРЫШСАМ ДА, АНЫ БУ РӘТКӘ СЫЙДЫРА АЛМАДЫМ.

Айсылу ул аерым. Ул башка! Һәм бу мактау сүзе түгел. Золушка яисә Элизага охшаса, шәп булыр иде асылда. Мин көчле әсәрнең сыйфатлы плагиатына уңай карыйм (акыл, акыл-л-л). Яманлыйсым да килми. Ике «мин»нең арасында калдым: тәнкыйтьче һәм татарның эшләгән һәр эшенә сукырларча гашыйк берәү. Ике утым, ике битлегем. Икесе дә субъектив булу сәбәпле, Сезгә беренчемне тәкъдим итәм. Анысы файдалырак шәйдер.

Татар халык җыры «Ак калфак» бөтен фильм аша бер җеп булып сузылган (гадәттә, рецензияләрдә еш очрый бу «җеп»ле чагыштыру, кыстырмасам, я рецензиягә охшамас!) Сценарист Алексей Барыкин, яшь режиссер Рөстәм Рәшитов нәрсә әйтергә теләде икән? Фильм башыннан ахырына кадәр истән чыкмады бу сорау. Калганы уч төбендә: чишелгән, әйтелгән, чәйнәлгән. Премьерадан соң оештырылган әңгәмәдә «ни өчен сайладыгыз бу җырны, сер булмаса?» дигән соравыма, «ошады да сайладык, бернинди мәгънә салмадык» диюләре, ай, юк итте дә соң бар булган хисләрне! Ялганлап, берәр риваять тәкъдим итсәгез, Рөстәм әфәнде, мин шуңа бик разый булган булыр идем ләбаса. Халык ярата бит ул ялганны! Фестивальсез-нисез, тиктомалдан, гап-гади бер февраль кичендә Казанның «Мир» кинотеатрында шундый хаос тудыру, ике залны шыгрым тутыру – саллы уңыш. Фильм эчтәлеген исәпкә алмаганда да (бушлай икәнен онытып торыйк, зинһар). Бу пиар кампаниянең яхшы оештырылуын һәм Казан халкының татар мөхитенә сусавын раслый. Мохит дигәннән, татар фильмын караганнан соң, татарча да сөйләшсәләр, «моһит» дигәне дә татар халкы белән бергә сөенер иде анысы. Ләкин әңгәмә барышында «татар киносы» сүзтезмәсе кимендә илле мәртәбә әйтелде, ә бу инде илле татар сүзе дигән сүз. Дәшмим, дәшмим.



Соры, кара, коңгырт, күе зәңгәр... Арасына көләч сары, янып торган кызыл, йомшак яшелләрне өстисе килде. Ай килде! Мин татар авылын мондый бетәшкән, тонык, үле төсләрдә күрергә иялəшмәгән. Режиссерга карышып булмый, әлбәттә. Бу фильмның идеясен, халәтен ассызыклый. Әлбәттә! Ләкин киң катлам тамашачының татар авылы турындагы күзаллавын...

Гөлназ Галимуллина искиткеч уйнады. Әмма татар кызын да, татар кешесен дә, татар авылы кебек үк, теләсә нинди татарга кагылышлы башка әйберне дә авыру, мескен, кимсетелгән, бетәшкән, елак хәлдә күрүдән туелган. Бу халәтләрне, төсләрне, хикәяләрне җыеп, калын бер китапка тутырып, шап итеп ябып, чормага менгезеп куясы килә. Нык, ышанычлы, дәртле, кайнар, уяу, алдынгы кешеләр, авыллар, шәһәрләр, тарихлар, хикәяләр, әллә-ниләр күрәсе килә... Һәм фильм ахырында түгел.

Караганнар арасыннан күпләрнең фикерен ишетәсе килеп калды. Халык күп булганга, залга керә алмаган Рәзил Вәлиев, һәм аеруча, янәшәмдә генә зур игътибар белән карап утырган Миләүшә Айтуганова фикерләре кызыклы булыр иде. Андый шәхесләрнең чын(!) фикере еш кына төпле була, тик әйтелми кала.

Эчтәлеген махсус ачмадым. Фильмның эчтәлеген сөйләмиләр, аны карыйлар. Ә шулай да әлеге фильмны тудырган һәр кеше алдында баш иям. Ни генә дисәм дә, мин сезне сөям, хөрмәт итәм. Бер баскычсыз икенчесе төзелми. Фильм бар, ә, димәк, уйланулар бар, мактау бар, тәнкыйть бар.

● Бәйге

# Татар теле сакчысына – IPhone

БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ ФОРУМЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ, «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН», «ДӘРЕЛФӨНҮН» ГАЗЕТАЛАРЫ РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ «ТАТАРЧА ХАТАСЫЗ!» ФОТОМАРАФОНЫН ИГЪЛАН ИТӘ.




Татарстанда рәсми кабул ителгән ике дәүләт теле бар: без җаныбыз теләгәнчә татар яки рус телләрен куллана алабыз. Республикада барлык элмә такталар, урам исемнәре, юл күрсәткечләре, реклама белдерүләре һ.б. ике телдә язылырга тиеш.

Әмма еш кына татар теленең кысрыклануын күрәбез: республика шәһәрләрендә элмә такталар бер телдә генә яки татар телендә хаталы язылган була. Кайсыбер рекламаларны күргәч, ни көләргә, ни еларга белмичә шаккатып каласың. Бу вәзгыятьне төзәтер өчен, татар яшьләренең актив өлеше әлеге фотомарафонны үткәрү инициативасы белән чыкты. Ә син ана телен яклаучылар сафына керергә телисеңме?

Күзеңә чалынган барлык хаталы язуларны фотога төшер, бер файлга җыеп, 10 нчы майга кадәр ***xatasiz2015@gmail.com*** электрон адресына юлла. Безнең максат – татар телендәге белдерүләр, элмә такталар, билбордлар, баннерлар, реклама белдерүләре, мәгълүмати такталар, юл күрсәткечләре, товар тышлыкларындагы грамматик, синтаксик, стилистик хаталарга каршы көрәш!

Фотомарафонның икенче этабына хаталы элмә такта фотоларын иң күп җибәргән катнашучылар узачак. Алар 16 нчы майда Казанга чакырылачак.

Фотомарафонның җиңүчеләрен компетентлы жюри билгеләячәк.

Җиңүчеләрне кыйммәтле бүләкләр көтә. Иң-иңнәргә – IPhone, фотоаппарат һәм электрон китаплар. Бүләкләү тантанасы 2015 нче елның 20 май көнендә Казанда булачак. Җиңүчеләргә шулай ук «Вымпелком» ААҖ (Билайн) тәкъдим иткән бүләкләр дә тапшырылачак. Беләсегез килсә, әлеге ширкәт соңгы берничә елда «Мин татарча сөйләшәм!» акциясенең төп иганәчеләреннән берсе булып тора. Шунысы да кызыклы: «Билайн» элемтә операторлары беренчеләрдән булып татар телендә хезмәт күрсәтә башлады.

Фотомарафон «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» буенча 2014-2020 нче елларга кабул ителгән дәүләт программасына нигезләнеп үткәрелә.

Тулырак мәгълүмат алу өчен, марафонның кураторларына мөрәҗәгать итәргә була:
Гүзәлия Гыйниятуллина +7 9172712124
Ленария Мөслимова +7 919 698 48 21
Тәбрис Яруллин +7 927 67522 48
Римма Бикмөхәммәтова+7 9375209914

Ихтирам белән, Бөтендөнья татар яшьләре форумының матбугат үзәге.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: Э.Р.Һадиева
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.